# Бәзәкәнең яшь сандугачы

“Мәйдан” әдәби-нәфис иҗтимагый журналының 2022 елның сентябрь номерында безнең якташыбыз, бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә торып эшләүче Резеда Шәмсуллинаның шигырьләре дөнья күрде. Бу яшь талантның беренче тапкыр республика дәрәҗәсенә чыгуы. Димәк, авылыбызда Марсель абый Гыймазетдинов, Фәния апа Шакирова, Мехәмәтнур абый Нәҗметдинов һәм башка бик күп якташларыбыз ачкан илһам чишмәләре яңа яшь талантлар иҗаты белән тулыландырылачак.

Барлык авылдашлар, якташлар исеменнән Бәзәкәнең яшь сандугачы Резеда Шәмсуллинага яңа иҗат уңышлары теләп калабыз!

№ 9

# Мәйдан

әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал

сентябрь/ 2022



*Тормыш әлифбасын*
*гомер буе өйрәнергә тырыш.*

Фәнис Яруллин

Резеда ШӘМСУЛЛИНА

# Хәтер буйлап сәяхәткә чыктым



Мин, **Резеда Шәмсуллина**, 1988 елның 5 маенда Яр Чаллы шәһәрендә туганмын. Казан федераль университетының (КДУ) Филология һәм журналистика факультетын тәмамладым. Хәзерге вакытта Әлмәттә яшим, «Әлмәт таңнары» газетасы редакциясендә SMM-белгеч булып эшлим.

## Хатирәләр

Хәтер буйлап сәяхәткә чыктым,
Яшьлек сукмакларын урап уздым.
Хатирәләр белән тулы сандык
Саклый җанда үткән вакыт кузын.

Әйтерсең лә кичә генә булган
«Зур үсәсе килә» дигән чагым.
Үскәнлекнең өстенлеген күреп,
Тик бер көнгә кайтыр идем тагын.

Һаман килә язлар, матур җәйләр,
Алтын көзләр килә һәр ел саен,
Соңга калмый килә ак кыш-патша,
Кайтмый балачагым табып җаен.

Яшьлек тә бит бары мизгел төсле:
Бүген син – студент, хыялдай көчле!
Дәртең белән таулар этәрәсең,
Ә иртәгә бишек тирбәтәсең.

Яраламыйк тиккә газиз җанны,
Һәр вакытның үзгә бер яме бар.
Үтсә-үтсен, әйдә, айлар, еллар,
Тик китмәсен бездән хатирәләр.

Ни кызыгы булыр яшәешнең,
Җан җылытыр хатирәңне җуйсаң?!
Үткәннәрне барлап яшәү рәхәт,
Туймам җиргә хәтта мең кат тусам.